ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

**(IV чакырылыш)**

кырык өченче утырыш

«09» июнь 2025 ел № 126 Айдар ав.

Айдар авыл җирлеге Теләче муниципаль район Советының 21.02.2011 № 12 «Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында "

Татарстан Республикасы Теләче районы прокуратурасының 28.03.2025 ел №02-01-15-2023/Прдп6-25-20920037 номерлы протестын карап, «Федераль закон "Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында" Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Айдар авыл җирлеге Теләче муниципаль район Советының 21.02.2011 № 12 «Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы турында» карарына (Айдар авыл җирлеге Советының 15.11.2013 № 102, 23.01.2015 № 152 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Айдар авыл җирлеге Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексында 21 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «д» пунктчасы белән тулыландырырга:

«д) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләргә аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән белешмәләрдән тыш (алга таба - анкетадагы белешмәләр).».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Айдар авыл җирлеге башлыгы Х.Ш. Хәсәншин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЙДАРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН» СОВЕТ АЙДАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1619002118